**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О единовременном поощрении лиц, проходящих (проходивших) государственную гражданскую службу Республики Татарстан

В соответствии с частью 9 статьи 25 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» **постановляю**:

1. Выплачивать государственным гражданским служащим Республики Татарстан (далее – государственные служащие), а также гражданам Российской Федерации, уволенным с государственной гражданской службы Республики Татарстан (далее – государственная служба) после представления к поощрению или награждению (далее также – граждане), единовременное поощрение в следующих размерах:

а) при поощрении Президентом Республики Татарстан, Председателем Государственного Совета Республики Татарстан, Кабинетом Министров Республики Татарстан – в размере 0,5 оклада месячного денежного содержания государственного служащего, состоящего из месячного оклада государственного служащего в соответствии с замещаемой им должностью государственной службы и месячного оклада государственного служащего в соответствии с присвоенным ему классным чином государственной службы (далее – оклад месячного денежного содержания государственного служащего);

б) при награждении государственной наградой Республики Татарстан – в размере 1,5 оклада месячного денежного содержания государственного служащего;

в) при поощрении Президентом Российской Федерации, Правительством Российской Федерации – в размере одного оклада месячного денежного содержания государственного служащего;

г) при награждении государственной наградой Российской Федерации – в размере двух окладов месячного денежного содержания государственного служащего.

2. Единовременное поощрение выплачивается исходя из размера оклада месячного денежного содержания государственного служащего, установленного на дату издания правового акта Российской Федерации или правового акта Республики Татарстан о поощрении или награждении, а в отношении граждан – на дату издания правового акта об их увольнении.

3. Выплата единовременного поощрения государственному служащему или гражданину осуществляется государственным органом Республики Татарстан, в котором указанное лицо замещает или замещало должность государственной службы (далее – государственный орган Республики Татарстан), в 30-дневный срок со дня издания правового акта Российской Федерации или правового акта Республики Татарстан о поощрении или награждении указанного лица за счет средств фонда оплаты труда государственных служащих соответствующего государственного органа Республики Татарстан.

4. В случае гибели (смерти) государственного служащего или смерти гражданина, которые были поощрены Президентом Российской Федерации, Правительством Российской Федерации, Президентом Республики Татарстан, Председателем Государственного Совета Республики Татарстан, Кабинетом Министров Республики Татарстан, награждены государственной наградой Российской Федерации или государственной наградой Республики Татарстан, а также в случае награждения указанных лиц государственной наградой Российской Федерации или государственной наградой Республики Татарстан посмертно выплата единовременного поощрения производится членам их семей, определенным в части 8 статьи 25 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан».

5. Выплата единовременного поощрения в случаях, указанных в пункте 4 настоящего Указа, производится не позднее чем через один месяц со дня истечения шестимесячного срока, в течение которого члены семьи погибшего (умершего) государственного служащего или умершего гражданина могут обратиться в государственный орган Республики Татарстан за выплатой единовременного поощрения. При этом указанный срок исчисляется со дня издания правового акта Российской Федерации или правового акта Республики Татарстан о поощрении или награждении таких государственного служащего или гражданина. При обращении нескольких членов семьи за единовременным поощрением, не полученным указанными государственным служащим или гражданином в связи с гибелью (смертью), сумма поощрения делится между членами семьи поровну.

6. В целях информирования граждан либо членов семей лиц, указанных в пункте 4 настоящего Указа, государственный орган Республики Татарстан не позднее 10 рабочих дней со дня издания правового акта Российской Федерации или правового акта Республики Татарстан о поощрении или награждении письменно уведомляет граждан, членов семей лиц, указанных в пункте 4 настоящего Указа, сведения о которых имеются в распоряжении этого государственного органа Республики Татарстан, о поощрении или награждении и разъясняет им порядок обращения за единовременным поощрением.

7. Выплата единовременного поощрения гражданину либо членам семей лиц, указанных в пункте 4 настоящего Указа, осуществляется путем перечисления им соответствующих сумм на лицевой счет, открытый в кредитной организации, либо путем выдачи в установленном порядке наличных денежных средств.

8. Единовременное поощрение представителям Республики Татарстан в субъектах иностранных федеративных государств или административно-территориальных образованиях иностранных государств, в иностранных государствах (далее – представители Республики Татарстан) выплачивается в рублях исходя из размеров окладов месячного денежного содержания представителей Республики Татарстан, исчисленных в соответствии с Указом Президента Республики Татарстан от 22 марта 2018 года № УП-239 «О денежном содержании государственных гражданских служащих Республики Татарстан».

Единовременное поощрение гражданам, уволенным с государственной службы и представленным к поощрению или награждению в период замещения должностей представителей Республики Татарстан, а также членам семей погибших (умерших) граждан, замещавших должности представителей Республики Татарстан, выплачивается в рублях исходя из размеров окладов месячного денежного содержания представителей Республики Татарстан, исчисленных в соответствии с Указом Президента Республики Татарстан от 22 марта 2018 года № УП-239 «О денежном содержании государственных гражданских служащих Республики Татарстан».

Месячные должностные оклады в иностранной валюте представителей Республики Татарстан, установленные Указом Президента Республики Татарстан от 25 декабря 2006 года № УП-583 «Об условиях оплаты труда представителей Республики Татарстан в субъектах иностранных федеративных государств или административно-территориальных образованиях иностранных государств, в иностранных государствах», при исчислении единовременного поощрения, предусмотренного абзацами первым и вторым настоящего пункта, не учитываются.

9. Настоящий Указ применяется в отношении государственных служащих, граждан, правовой акт о поощрении или награждении которых издан после вступления в силу настоящего Указа.

10. Настоящий Указ вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
17 января 2023 года
№ УП-31

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен узучы (узган) затларны бер тапкыр акчалата бүләкләү турында

«Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясының 9 өлеше нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре), шулай ук бүләкләүгә тәкъдим ителгәннән соң Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән (алга таба – дәүләт хезмәте) азат ителгән Россия Федерациясе гражданнарына (алга таба шулай ук – гражданнар) бер тапкыр түбәндәге күләмнәрдә акча түләргә:

а) Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан бүләкләнгәндә – дәүләт хезмәткәренең ул биләгән дәүләт хезмәте вазыйфасы нигезендә айлык окладыннан һәм дәүләт хезмәткәренең аңа бирелгән дәүләт хезмәте классны чины нигезендә айлык окладыннан торган дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата гомуми хезмәт хакының 0,5 окладьы (алга таба – дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата гомуми хезмәт хакы окладьы) күләмендә;

б) Татарстан Республикасының дәүләт бүләге белән бүләкләнгәндә – дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата гомуми хезмәт хакының 1,5 окладьы күләмендә;

в) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан бүләкләнгәндә – дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата гомуми хезмәт хакының бер окладьы күләмендә;

г) Россия Федерациясе дәүләт бүләге белән бүләкләнгәндә – дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата гомуми хезмәт хакының ике окладьы күләмендә.

2. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү дәүләт хезмәткәренең аны бүләкләү турында Россия Федерациясе хокукый акты яки Татарстан Республикасы хокукый акты чыгарылу датасына, ә гражданнарга карата – аларның эштән азат ителү турында хокукый акт чыгарылу датасына билгеләнгән айлык акчалата гомуми хезмәт хакы окладьы күләменнән чыгып түләнә.

3. Дәүләт хезмәткәренә яисә гражданга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү әлеге зат дәүләт хезмәте вазыйфасын били торган яисә биләгән Татарстан Республикасы дәүләт органы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт органы) тарафыннан әлеге затны бүләкләү турында Россия Федерациясе хокукый акты яки Татарстан Республикасы хокукый акты чыгарылган көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасының тиешле дәүләт органының дәүләт хезмәткәрләре хезмәтенә түләү фонды акчасы хисабыннан башкарыла.

4. Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан бүләкләнгән, Россия Федерациясе дәүләт бүләге яисә Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләнгән дәүләт хезмәткәре һәлак булган (вафат булган) яисә граждан вафат булган очракта, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт бүләге яисә Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән вафат булганнан соң бүләкләнгән очракта бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү әлеге затларның «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясының 8 өлешендә күрсәтелгән гаилә әгъзаларына түләнә.

5. Әлеге Указның 4 пунктында күрсәтелгән очракларда бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү һәлак булган (вафат булган) дәүләт хезмәткәренең яисә вафат булган гражданның гаилә әгъзалары Татарстан Республикасы дәүләт органына бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләүне сорап мөрәҗәгать итә ала торган алты айлык срок тәмамланган көннән соң бер айдан да соңга калмыйча түләнә. Бу вакытта әлеге срок мондый дәүләт хезмәткәрен яисә гражданны бүләкләү турында Россия Федерациясе хокукый акты яисә Татарстан Республикасы хокукый акты чыгарылган көннән башлап исәпләнә. Әлеге дәүләт хезмәткәре яисә граждан тарафыннан һәлак булуы (вафат булуы) сәбәпле алынмыйча калган бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне алу өчен гаилә әгъзаларының берничәсе мөрәҗәгать иткәндә, акчалата бүләкләү суммасы гаилә әгъзаларына тигез итеп бүленә.

6. Гражданнарга яисә әлеге Указның 4 пунктында күрсәтелгән затларның гаилә әгъзаларына хәбәр бирү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт органы бүләкләү турында Россия Федерациясе хокукый акты яисә Татарстан Республикасы хокукый акты чыгарылган көннән 10 эш көненнән соңга калмыйча гражданнарга, әлеге Указның 4 пунктында күрсәтелгән затларның әлеге Татарстан Республикасы дәүләт органында алар турында мәгълүмат булган гаилә әгъзаларына бүләкләү турында язма рәвештә хәбәр җибәрә һәм аларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне алу өчен мөрәҗәгать итү тәртибен аңлата.

7. Гражданга яисә әлеге Указның 4 пунктында күрсәтелгән затларның гаилә әгъзаларына тиешле суммаларны кредит оешмасында ачылган шәхси счетларына күчерү юлы белән яисә билгеләнгән тәртиптә акчаны кулларына бирү юлы белән башкарыла.

8. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү Татарстан Республикасының чит ил федератив дәүләтләр субъектларындагы яисә чит ил дәүләтләренең административ-территориаль берәмлекләрендәге, чит ил дәүләтләрендәге вәкилләренә (алга таба – Татарстан Республикасы вәкилләре) Татарстан Республикасы вәкилләренең Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указы нигезендә хисапланган айлык акчалата гомуми хезмәт хакы күләменнән чыгып сумнарда түләнә.

Дәүләт хезмәтеннән азат ителгән һәм Татарстан Республикасы вәкилләре вазыйфаларын башкару чорында бүләкләүгә тәкъдим ителгән, шулай ук Татарстан Республикасы вәкилләре вазыйфаларын биләгән һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү Татарстан Республикасы вәкилләренең Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указы нигезендә хисапланган айлык акчалата гомуми хезмәт хакы күләменнән чыгып сумнарда түләнә.

Татарстан Республикасы вәкилләренең Татарстан Республикасы Президентының «Чит ил федератив дәүләтләре субъектларында яисә чит ил дәүләтләренең административ-территориаль берәмлекләрендә, чит ил дәүләтләрендә Татарстан Республикасы вәкилләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2006 елның 25 декабрендәге ПУ-583 номерлы Указында билгеләнгән чит ил валютасында айлык вазыйфаи окладлары әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацларында каралган бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне хисаплаганда исәпкә алынмый.

9. Әлеге Указ аларны бүләкләү турындагы хокукый акт әлеге Указ үз көченә кергәннән соң чыгарылган дәүләт хезмәткәрләренә, гражданнарга мөнәсәбәтле кулланыла.

10. Әлеге Указ рәсми бастырып чыгарылган көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел,17 гыйнвар
№ ПУ-31